| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.03.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 431** |

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче ачык (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучыларына кайнар тукландыруны оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның баланслы кайнар тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары нигезендә, «Адреслылык принцибын саклау һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычыннан чыгып социаль яклау чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә һәм «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 14 февралендәге 181-ФЗ номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче ачык (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучыларына 27.02.2020 елдан башлап һәр уку көненә 37,7 сум, шул исәптән 7,70 сум - Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән, 30,0 сум - башка чыганаклар исәбеннән кайнар тукландыруны оештырырга.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче ачык (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Р.Ю.Җәләлиевка:

2.1. Укучыларның туклануын оештыру өчен җаваплы зат билгеләргә.

2.2. Укучыларның ризык кабул итү графигын раслау.

3. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 10 нчы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры

С.В. Будькога укучыларга гимназиянең аш залында булу өчен шартлар тудырырга.

4. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче ачык (сменалы) гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе укучылары өчен уку вакытында кайнар туклануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

5. Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба - ЕГИССО) файдалану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

6. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның гамәли көче 27.02.2020 елдан үз көченә керә.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин